## "ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

**2015 елның 4 апреле** **143№**

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ҖИТӘКЧЕСЕ ВАЗЫЙФАСЫНА КЕРҮЧЕ ЗАТ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ҖИТӘКЧЕСЕ ВАЗЫЙФАСЫНА КЕРҮЧЕ ЗАТНЫҢ ХАТЫНЫ (ИРЕН) ҺӘМ БАЛИГЪ БУЛМАГАН БАЛАЛАРЫНЫҢ КЕРЕМНӘРЕ, МӨЛКӘТЛӘРЕ ҺӘМ МӨЛКӘТИ ХАРАКТЕРДАГЫ ЙӨКЛӘМӘЛӘРЕ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ БИРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘНЕ РАСЛАУ ХАКЫНДА

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 275 статьясы, Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге "Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында" 460 номерлы Әмере, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 мартындагы "Федераль дәүләт учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керә торган зат, шулай ук федераль дәүләт учреждениесе җитәкчесе тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм керемнәре, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне бирү кагыйдәләрен раслау хакында" 208 номерлы карары нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче затның һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне расларга

2. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23 мартындагы "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына килүче затның һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы хакындагы Нигезләмәне раслау турында"177 нче номерлы карарын юкка чыккан дип танырга.

3. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар имза салынган вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе
А. Ф. НИКОШИН

Расланган
Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Башкарма комитетының
2015 елның 4 апрелендәге 143 номерлы карары
.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ҖИТӘКЧЕСЕ ВАЗЫЙФАСЫНА КЕРҮЧЕ ЗАТ ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ҖИТӘКЧЕСЕ ВАЗЫЙФАСЫНА КЕРҮЧЕ ЗАТНЫҢ ХАТЫНЫ (ИРЕН) ҺӘМ БАЛИГЪ БУЛМАГАН БАЛАЛАРЫНЫҢ КЕРЕМНӘРЕ, МӨЛКӘТЛӘРЕ ҺӘМ МӨЛКӘТИ ХАРАКТЕРДАГЫ ЙӨКЛӘМӘЛӘРЕ ТУРЫНДА МӘГЪЛҮМАТ БИРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 275 статьясы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфасына керә торган затларны (алга таба - муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре) аларның алынган керемнәре турында, милек хокукындагы мөлкәтләре турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милек хокукындагы мөлкәтләре турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр (алга таба - керемнәр, мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр) тапшыру тәртибен билгели

2. Эшкә кергәндә муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керә торган зат тапшыра:

а) муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре (элеккеге эш урынындагы яисә сайланулы вазыйфаны биләү урынындагы керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган белешмә формасы буенча муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына милек хокукындагы мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

б) үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшырган елга кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) алынган керемнәре турында, шулай ук Россия Федерациясе Президенты раслаган белешмә формасы буенча муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр.

3. Муниципаль учреждение җитәкчесе ел саен, хисап чорыннан соң килүче 30 апрельдән дә соңга калмыйча, тапшыра:

а) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук милек хокукындагы мөлкәт турында һәм Россия Федерациясе Президенты раслаган белешмә формасы буенча хисап чоры ахырына үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

б) үзенең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында белешмәләр, шулай ук милек хокукында булган мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган белешмә формасы буенча хисап чоры ахырына торышы буенча белешмәләр.

4. Әлеге Нигезләмәнең 2 һәм 3 пунктларында каралган белешмәләр эш бирүченең вәкаләтле структур бүлекчәсенә бирелә.

5. Муниципаль учреждение җитәкчесе тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрдә күрсәтелмәгән яисә нинди дә булса белешмәләр тулысынча чагылдырылмаган йә хаталар булган очракта, ул әлеге Нигезләмәнең 3 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

5.1. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керешкән зат алар тапшырган белешмәләрдә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр күрсәтелмәгән яисә нинди дә булса белешмәләр күрсәтелмәгән йә хаталар булган очракта, ул әлеге Нигезләмәнең 2 пункты нигезендә белешмәләр тапшырылган көннән алып бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы.

6. Әлеге Нигезләмә нигезендә муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керә торган зат, шулай ук муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр, әгәр Федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләргә кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр булып тора.

Әлеге белешмәләр федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда вазыйфаи затларга бирелә.

7. Муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

8.Вазыйфаи вазыйфаларына керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр белән эшләү керә торган гамәлгә куючының вазыйфаи затлары, аларны Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда фаш итүдә яки файдалануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.

9. Әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр һәм әлеге белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат муниципаль учреждение җитәкчесенең шәхси эшенә кушып бирелә.

10. Әлеге Нигезләмә нигезендә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр биргән зат муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына билгеләнмәгән очракта, күрсәтелгән белешмәләр аңа язма гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла, ә язма гариза булмаганда юкка чыгарылырга тиеш.

11. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына кергәндә керемнәр турында, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшыру күрсәтелгән затны муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

12. Муниципаль учреждение җитәкчесе керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында тулы булмаган яисә дөрес булмаган белешмәләр тапшырса, аңа эш бирүче тарафыннан ышанычны югалтуга бәйле рәвештә, аның белән төзелгән хезмәт шартнамәсен өзү өчен нигез була (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясы 1 өлешенең 7.1 пункты).

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына килүче затның һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау хакында